Лубян авыл җирлеге Советы

КАРАР

2019 елның 28 ноябре №21

«Җир салымы турында» 2013 елның
21 ноябрендәге 20 номерлы
Лубян авыл җирлеге Советы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Лубян авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Җир салымы турында» 2013 елның 21 ноябрендәге 20 номерлы Лубянл авыл җирлеге Советы карарына (Лубян авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 ноябрендәге 30 номерлы, 2015 елның 30 маендагы 18 номерлы, 2015 елның 18 ноябрендәге 23 номерлы, 2017 елның 27 июнендәге 5 номерлы, 2018 елның 16 ноябрендәге 26 номерлы, 2018 елның 29 ноябрендәге 31 номерлы, 2018 елның 20 декабрендәге 34 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) кадастр бәясеннән 0,1 процент – торак фонды һәм торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләрдән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) җир кишәрлекләренә карата;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, шулай ук Лубян авылы җирлеге торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән соң кимендә бер ай узгач, үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: В.П.Костин